| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 27.12.2023 | г. Казань | № 833-7/нпс-2023 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2023 №109-3/нпс-2023 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә чик дәрәҗәдә максималь бәяләр һәм торак фондының техник инвентаризациясенә ставкалар билгеләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 27.12.2023 №65-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 09.08.2023 №109-3/нпс-2023 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.09.2023 №319-4/нпс-2023 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә кадастр эшләренә чик дәрәҗәдә максималь бәяләр һәм торак фондының техник инвентаризациясенә ставкалар билгеләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«Бәяләр, Ставкалар календарь елына яки озак вакытлы җайга салу чорына (5 елдан артык түгел) билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бәяләрне, Ставкаларны озак сроклы җайга салу чорына билгеләгәндә, ел саен төзәтмәләр кертү әлеге Тәртипнең VI бүлегенә ярашлы рәвештә башкарыла.»;

3.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Бәяләр, Ставкалар Дәүләт комитеты тарафыннан чираттагы ел башына кадәр, әмма чираттагы җайга салу чорына (2025 ел һәм аннан соңгы елларга җайга салу чорына) кадәрге елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча билгеләнә.»;

3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12. Бәяләрне, Ставкаларны җайга салганда түбәндәге методлар кулланыла:

1) икътисадый нигезләнгән чыгымнар (сарыфлар) методы. Икътисадый нигезләнгән Бәяләр, Ставкалар әлеге Тәртипнең IV һәм V бүлекләренә ярашлы рәвештә исәпләнә;

2) тарифларны индексацияләү ысулы, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан җайга салу чорына эшләнгән Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше фаразына ярашлы рәвештә, куллану бәяләре индексы-дефляторына билгеләнгән тарифларны индексацияләү юлы белән исәпләүне күздә тота.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хәбибуллина